Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«05» ноябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Яңа Тумба торак пунктында ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү төзекләндерү .

Халык җыенында рәислек итүче: Л.Н. Осипов

Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Осипов